УДК 821.512.145
DOI: 10.33184/fnspnpi-2022-11-17.20

# И. ГАСПРАЛЫНЫҢ ИСЛАХ ЭШЧӘНЛЕГЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*© М.С. Шарипов*
*кандидат филологических наук*
*доцент кафедры татарской филологии и культуры*
*Уфимский университет науки и технологий*
*450076, Республика Башкортостан, г. Уфа, ул. Заки Валиди, д. 32*
maratsharif@yandex.ru

*В данной статье рассматривается реформаторская деятельность Исмаила Гаспринского, выдающегося просветителя, педагога, писателя, издателя, общественного деятеля, яркого представителя крымско-татарского народа. Необходимость исследования данной темы связана с созвучием сегодняшнему дню, актуальностью многих положений научно-исследовательских трудов И. Гаспринского, его мыслей о необходимости мирного сосуществования и взаимной коммуникации между народами, толерантности, уважительного отношения к истории, национальной самобытности, религии соседних народов.*

*Как отмечают биографы, всю жизнь И. Гаспринский был приверженцем принципов либеральной идеологии: эволюционного развития общества, дружбы тюркских и славянских этносов, конфессиональной толерантности мусульман и христиан. В изданной им первой тюркской газете «Терджиман» широко освещалась картина мира многих тюркоязычных народов конца XIX - начала XX века, в том числе мусульман Средней Азии, Поволжья и Урала. Издание ставило целью объединение тюркских народов на основе духовного и исторического единства, зарождения национального самосознания, сохранение и развитие их языка, самобытной культуры и многовековых традиций. И. Гаспринский ввёл в систему обучения мусульманских учебных заведений России начала XX века метод джадидизма, ставший*

*впоследствии символом прогрессивного направления педагогического образования.*

*И. Гаспринский – основатель крымско-татарского литературного языка, автор крымско-татарского алфавита, множества учебно-методических трудов и, наконец, он – классик крымско-татарской литературы, известный прозаик, воплощавший в своих романах, повестях и рассказах яркий национальный характер крымских татар, воспевший через остросюжетные повествования стремление своего народа к просвещению, к свободе.*

*Выдающегося просветителя всегда окружали единомышленники. В статье выявляются особенности взаимоотношений Исмаила Гаспринского и золотопромышленников, меценатов братьев Рамиевых - Шакира Рамиева и Дэрдменда (Закира Рамиева).*

***Ключевые слова:*** *гуманизм, нация, метод, татарская культура, меценатская деятельность, роман, издательство.*

XIX гасыр ахыры - XX гасыр башында, XXI гасыр башы теле белән әйткәндә, бөтен дөньяның иҗтимагый-сәяси тәртибен үзгәртеп кору процессы башлана. Ул чакта җир шарының төрле почмакларында сугышлар кабынды, колонияләр бүленде, чикләр үзгәрде, революцияләр башланып, кеше язмышлары сәяси гарасат эченә керде. Нәтиҗәдә, инсаниятнең киләчәккә өмете өзелде. Бу вакыттагы иҗтимагый үсешнең борылыш нокталарында, тарихи барышта пассионар эшчәнлекләре белән халыклар үсеше юнәлешенә гаять зур йогынты ясаучы шәхесләр аренага чыга. Русиядә яшәүче төрки телле халыкларның үсеш тарихында Исмәгыйль Гаспралы (Гаспринский) һәм бертуган Рәмиевләр шундый шәхесләрдән булганннар. Империянең төрле почмакларында яшәгән бу кешеләрне тирән рухи бәйләнеш һәм милли идея белән бәйле мөнәсәбәтләр берләштерә.

XIX гасырның икенче яртысында Русиядә төрки-мөселман җәмәгатьчелегенең рухи үзәге «Тәрҗеман» гомумтөрки газетасы (хәзерге вакытта бу газетаның тулы тупланмасы Төркиянең Эгей университеты китапханәсендә саклана) була, аның нәшер итүчесе һәм мөхәррире И. Гаспралы була. Атна саен башта рус һәм кырым-татар телләрендә, аннары фәкать кырым-татар телендә чыгучы бу

газетаның тиражы 12-20 мең данә тәшкил итә. Басма мөселманнар тормышының бөтен палитрасын тулысынча чагылдыра. Кырымнан читтә – Төркстанда, Персиядә, Кытайда, Төркиядә, Мисырда, Болгариядә, Франциядә, Швейцариядә, АКШта – актив яздырылган, укылган беренче төрки телле газета искиткеч уңышка ирешкән: ул 35 ел дәвамында даими чыккан һәм 1918 елда гына яшәүдән туктарга мәҗбүр булган. Кызыклы факт, Казанда, Уфада һәм Русиянең башка шәһәрләрендә яшәүче татарлар бары XX гасыр башында гына үз газета-журналларын милли телдә бастыра алдылар. Ә 1883 елда ук билгесез, әмма үҗәтле һәм куелган максатларга ирешергә күнеккән яшь Исмәгыйль Гаспралы символик исемдәге «Тәрҗеман» («Тәрҗемәче») исемле беренче милли газетаны ачуга ирешә. «Тәрҗеман» газетасыннан тыш, ул «Милләт» һәм «Алем-и-нисван» («Хатын-кызлар дөньясы»), «Алем-и-субьян» («Балалар дөньясы») журналларын да чыгара. Үз типографиясендә И.Гаспралы, газета-журналлардан тыш, белемгә омтылган татарлар өчен мәгърифәтчелек һәм тәрәккый фикерләр белән сугарылган күп кенә китаплар, уку әсбаплары да бастырып чыгара.

И. Гаспралы һәм Казан, Уфа шәһәрләренең интеллигенциясе вәкилләре арасында иҗади бәйләнеш булганмы? Әйе, бәйләнеш, һичшиксез, булган. Милләтпәрвәр кешеләрне бәйләп торган рухи җепләр аша, газета, китаплар аша. Уфа мөселманнары тормышы, татарлар, башкортлар эшчәнлеге «Тәрҗеман» газетасы битләрендә вакыт-вакыт белән яктыртыла. Дәрдемәнднең беренче шигырьләре дә, әйткәндәй, бу басмада дөнья күрә (1902-1903). Үзенең кылган гамәлләре, тормышта тоткан позициясе белән ул бөтен төрки дөньяга үз халкына ничек хезмәт итү юлын үрнәк итеп күрсәтте. Моннан тыш, И. Гаспралының Казанга килү факты зур әһәмияткә ия, аның милли газетаны оештыру идеясе белән күренекле татар галиме һәм мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗанигә мөрәҗәгате билгеле. Казанның шәрәфле кешесе бу проектны югары бәяләгән һәм аның тромышка ашырылуына фатихасын биргән. «Тәрҗеман» басмасына матди һәм оештыру ярдәмен меценатлар Әсәдуллаев һәм Таһиев, Оренбург сәүдәгәрләре Хөсәеновлар һәм алтын чыгаручылар бертуган Рәмиевләр күрсәтә. И. Гаспралы үз газетасын булдыру эшендә кызыклы очракны тасвирлый. 1882 елда Казанда ул шәһәр татарлары өчен әдәби кичә оештырырга

карар итә. Афишаны асып куялар, чакыру билетларын тараталар. Күптән көтелгән чарага нибары өч тамашачы килә, шуларның икесе – Оренбургтан Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) һәм Шакир Рәмиев. Нәрсә турында сүз баргандыр, үз заманының пассионар шәхесләре нинди темаларга кагылгандыр? Тарихта бу хакта язылмаган, истәлекләр дә юк. Мөгаен, кадерле очрашуда милләт язмышлары турында зур сөйләшү булгандыр. Төрле истәлекләр аша Рәмиевләрнең «Тәрҗеман» газетасын тарату һәм бастыру өчен финанс ярдәме күрсәтүләре билгеле. Идел буе һәм Урал татарлары белән рухи элемтәләрне ныгыту эшендә И.Гаспралының хатыны - фабрикант Акчуриннар нәселе вәкиле Зөһрә Акчурина - зур ярдәм күрсәтә. «Тәрҗеман» газетасын чыгару фондына ул үзенең кыйммәтле әйберләрен салган, газета саннарын чыгаруда, материал әзерләүдә дә актив катнашкан.

И. Гаспралы хезмәтләрен анализлап, галим Азат Ахунов мәгърифәтче фикерләренең бүгенге көннәрдә актуальлеген һәм заманыбызга аваздаш булуын ассызыклый: «Рус-Көнчыгыш килешүе» китабында Исмаил бәй алдагы китапта башланган теманы дәвам итә. Ул билгеләп үткәнчә, үзенең менталитеты буенча Русиядә мөселманнар һәм руслар, мәсәлән, руслар һәм аурупалыларга караганда, бер-берсенә якынрак. Гаспралы фикеренчә, Көнбатышка Русиядә мөселманнар һәм христианнар арасында каршылык һәм дошманлык халәте отышлы. Ул Русия хакимнәренә яңа сату базарларын эзләп Аурупага түгел, ә Көнчыгышка борылырга тәкъдим итә. Көнчыгыш белән дуслык Русия өчен күпкә отышлы булырга мөмкин, дип саный Гаспралы. Өстәвенә, бу ике як өчен дә файдалы. Хаталар һәм, бәлкем, фаҗигаләр булмасын өчен, ул хөкүмәтне ислам динен тотучы мөселман халыкларының гореф-гадәтләрен хөрмәт итәргә өндәде. И.Гаспралы болай дип язган: «Дәүләттә яшәүче кабиләләрнең милләтенә һәм тигезлегенә карата хөрмәттән чыгып, без аның, дәүләт бердәмлеге эшенә яхшы хезмәт иткәндә, шул ук вакытта, иң яхшы хезмәт һәм тормыш рәвешләрен формалаштыруга, алгарышка һәм үстерүгә ярдәм итүен күрәбез; дөреслеккә һәм гаделлеккә корылган бу система дөньяның күпчелек цивилизацияле халыклары арасында уңышлы эш итә» [1, 18].

Һәм, ниһаять, И. Гаспралы – кырым-татар әдәби теленә нигез салучыларның берсе. Талантлы язучы-новтор буларак ул

«Француз хатлары» романы, «Дар уль Рахат мөселманнары» утопик повесте, «Африка хатлары», «Амазон иле» повесте, «Арслан кыз» хикәясе, «Шәрекъ бәласе» новелласы, «Рус мөселманлыгы. Мөселманның уйлары, язмалары һәм күзәтүләре» исемле эссе, «Рус-Көнчыгыш килешүе. Фикерләр, искәрмәләр һәм теләкләр» һәм башка әсәрләр иҗат итә. Соңгы елларда, Европада һәм Көнчыгышта киеренкелек арткач, хәтта сугыш учаклары кабынгач, замандашларның карашлары үткән гасыр пассионар шәхесләренең вәсыять шәкелендәге тарихи модельләренә, толерантлык һәм үзара хөрмәт итү формулаларына юнәлде.

И. Гаспралының бөтен тормышын, күпкырлы эшчәнлеген, биографлар билгеләп үткәнчә, либераль идеологиянең алтын кагыйдәләре озата барган: җәмгыятьнең эволюцион үсеше, славян һәм төрки халыклар дуслыгы, христианнарның һәм мөселманнарның конфессиональ толерантлыгы. Кызык булмаган факт: 1910 елда И. Гаспралы Франциянең "Pevul du monde musulman" журналы тарафыннан күпкырлы гуманитар эшчәнлеге өчен Нобель премиясенә тәкъдим ителә. И. Гаспралы Бохараның «Күтәрелүче йолдыз алтын ордены» (III дәрәҗә); Төркиянең «Меджид» (IV дәрәҗә); Иранның «Арыслан һәм кояш» (IV һәм III дәрәҗә) һәм «Санкт-Петербург рус техник җәмгыяте медале» (бронза) белән бүләкләнгән. Ул Беренче бөтендөнья сугышы башланган елда үлде. Билгеле булганча, Беренче бөтендөнья сугышы елларында татарлар һәм башкортлар күпләп яшәгән урыннардан хәрби хезмәткә миллион ярымга якын кеше чакырылган булган. Алар, соңгы елларда бастырылган мәкаләләргә нигезләнеп, госпитальләрдә үлгән, эзсез югалган, үлгән кешеләр арасында 850 меңгә якын кеше булган дип фаразларга була [2, 421]. И. Гаспралының гуманистик идеалларына, гуманистик фикерләренә яңа территорияләрне бүлү идеологлары колак салмадылар. 1914 елның 11 сентябрендә кырым-татар халкының бөек улы Бакчасарайда танылган «Зенджырлы» мәдрәсәсе территориясендә күмелә. Билгеле ки, анда беренче Кырым ханнары җирләнгән. Бу хәл очраклы түгел, чөнки И. Гаспралы үз милләтенә тугры мәгариф хезмәтчеләренең бөек гаскәр вәкиле-солтаны иде, ул үз халкының рухи үсешенә генә түгел, ә шулай ук Русиянең төрки телле күп халыкларына, аларның мәгърифәт, мәдәният юлындагы күтәрелешенә дә зур йогынты ясады.

Әдәбият

1. Ахунов А. Исмаил Гаспралы // Татарстан. 2003. №4. С. 14-19.
2. Отечественные войны 1812-1814 1914-1917 гг. Память и уроки: Материалы Всероссийской научно-практической конференции «Первая мировая война как первый военный конфликт мирового масштаба» (г.Уфа, 16 октября 2014 г.). – Уфа: ИИЯЛ УНЦ РАН, 2014. – 464 с.

## FEATURES OF I.GASPRINSKY'S REFORM ACTIVITY

*© M.S. Sharipov*
*Candidate of Philological Sciences*
*Associate Professor of the Chair of Tatar Philology and Culture.*
*Candidate of Philological Sciences*
*Associate Professor of the of Foreign Languages*
*Ufa University of Science and Technology*
*450076, Republic of Bashkortostan, Ufa, Zaki Validi str., 32*
*maratsharif@yandex.ru*

*This article examines the reform activity of Ismail Gasprinsky, an outstanding educator, teacher, writer, publisher, public figure, a bright representative of the Crimean Tatar people. The need to study this topic is connected with the consonance to the present day, the relevance of many provisions of I. Gasprinsky's research works, his thoughts on the need for peaceful coexistence and mutual communication between peoples, tolerance, respect for history, national identity, religion of neighboring peoples.*

*According to biographers, all his life I. Gasprinsky was an adherent of the principles of liberal ideology: the evolutionary development of society, friendship of Turkic and Slavic ethnic groups, confessional tolerance of Muslims and Christians. The first Turkic newspaper "Tarjiman" published by him widely covered the picture of the world of many Turkic-speaking peoples of the late XIX - early XX century, including Muslims of Central Asia, the Volga region and the Urals. The publication aimed to unite the Turkic peoples on the basis of spiritual and historical unity, the emergence of national identity, the preservation and development of their language, original culture and*

*centuries-old traditions. I. Gasprinsky introduced the method of Jadidism into the teaching system of Muslim educational institutions in Russia at the beginning of the twentieth century, which later became a symbol of the progressive direction of pedagogical education.*

*I. Gasprinsky is the founder of the Crimean Tatar literary language, the author of the Crimean Tatar alphabet, many educational and methodological works, and, finally, he is a classic of Crimean Tatar literature, a well–known prose writer who embodied the vivid national character of the Crimean Tatars in his novels, novellas and short stories, who glorified the desire of his people for enlightenment, to freedom through action-packed narratives. The outstanding educator has always been surrounded by like-minded people. The article reveals the peculiarities of the relationship between Ismail Gasprinsky and the gold miners, patrons of the Ramiev brothers - Shakir Ramiev and Deardmend (Zakir Ramiev).*

***Keywords:*** *humanism, nation, method, Tatar culture, philanthropic activity, novel, publishing house.*